КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1025

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 528 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 528 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 март, 256 нчы; 2024 ел, 13 апрель, 254 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын

үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 6 июнь, 528 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 20 ноябрь, 1025 нче
карары редакциясендә)

## «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

### I. Субсидия бирүнең гомуми нигезләмәләре һәм шартлары

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – чара, сайлап алуда катнашучылар, субсидия) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидия түбәндәге кысаларда чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт

программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы.

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба шул ук эзлеклелектә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Субсидияләр алучыларны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

6. Субсидия алучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштыру датасына кадәр кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

заявка биргән датага кадәр кимендә биш ел рәттән Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар үткәрә тәҗрибәсе булу.

7. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

8. Министрлыкның һәм заявкаларны карау комиссиясенең (алга таба – комиссия) сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (кайтару).

11. Финанслар белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булып субсидия торган чыгымнар (акча тотулар) юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм чараларны үткәрүгә бәйле башка мәҗбүри түләүләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә башка түләүләр (шул исәптән авторлык һәм катнаш хокуклардан файдаланган өчен түләү);

чаралар үткәрү өчен корылмаларны (вакытлычаны кертеп), җир кишәрлекләрен, урыннарны (мәйданчыкларны) арендалау хезмәтләре, коммуналь

һәм эксплуатация чыгымнары өчен түләү;

чараны тормышка ашыру өчен кирәкле техник чаралар һәм ярдәмче җиһазлар сатып алу, шулай ук аларны монтажлау, демонтажлау, җибәрү-көйләү һәм хезмәт күрсәтү;

чараны гамәлгә ашыру өчен полиграфия продукциясе һәм канцелярия товарлары әзерләү һәм сатып алу, методик һәм мәгълүмати әдәбият (газеталар, буклетлар, журналлар, шул исәптән вакытлы нигездә) чыгару;

билет һәм тамашачы программаларын оештыруга (билетлар әзерләү, бастыру һәм тарату, тамашачыларның билетлар буенча керү системасын оештыру һәм техник яктан тәэмин итү (ул булмаган очракта)), чараны гамәлгә ашыру урыннарында саклау камерасы эшен оештыру, чараны гамәлгә ашыру урыннарында билет кассасы эшен оештыру, тамашачылар өчен мәгълүмат такталары эшен оештыруга чыгымнар;

бүләкләү атрибутикасы, сувенир продукциясе, призлар (шул исәптән акчалата призлар), чараны уздыру һәм анда катнашу өчен экипировка әзерләү һәм сатып алу;

җәлеп ителгән белгечләрнең һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы (хезмәт һәм эшлекле сәфәрләрне оештыруга чыгымнарны да кертеп);

белгечләрне һәм чарада катнашучыларны укытуны оештыруга түләү;

бүлмәләрне, транспорт чараларын, мәйданчыкларны, корылмаларны, шул исәптән вакытлыча булганнарын кертеп, чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле төрле конструкцияләрне, аларның монтажын һәм демонтажын да кертеп, бизәү (шул исәптән флористик бизәлеш, аэродизайн, декорация, костюмнар һәм реквизитлар);

реклама кампаниясе үткәрү, басма һәм башка мәгълүмати продукция (баннерлар, биллбордлар, бораулар, стендлар) әзерләү һәм тарату, монтаж һәм демонтаж, фото- һәм видеога төшерү, слайдлар, видеороликлар, видеофильмнар, телетапшырулар, музыкаль композицияләр һәм видеоклиплар җитештерү һәм ротацияләү (телеканаллар эфирында, «Интернет» челтәрендә, мәгълүмати таблода);

ачу һәм ябу тантаналарын, мәдәни программаны һәм чарага экскурсия хезмәте күрсәтүне оештыру;

программа һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү, IT-технологияләр (электр челтәре инфраструктурасы белән җиһазлау/җиһазландыру, телевизион һәм интернет-трансляцияләр оештыру);

чараны медицина белән тәэмин итү һәм медик-биологик тәэмин итү, ашыгыч ярдәм машинасы хезмәтләре, медицина хезмәткәрләре кизү торуы өчен түләү;

чараның куркынычсызлыгын тәэмин итү;

чарада катнашучыларның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр өчен түләү, аренда, товарлар сатып алу, шул исәптән Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе таләпләре нигезендә вируслы авыруларның таралуын профилактикалау өчен;

элемтә, радиоэлемтә хезмәтләрен, «Интернет» челтәреннән, лингвистик хезмәт күрсәтүләрдән файдалануны тәэмин итү;

чараларда катнашучыларны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү;

чараларны гамәлгә ашыру өчен транспорт чараларын арендалау, аларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, кирәкле техник чараларны ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү.

чарада катнашучыларның ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларында профильле сменаларга юлламалары яки аларның бер өлеше өчен түләү;

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган чараларда катнашучылар, шулай ук чаралар регламенты (нигезләмәсе) буенча мәҗбүри булган техник белгечләр өчен яшәү, туклану һәм юл йөрү өчен түләү.

12. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (S) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Z_1 + Z_2 + Z_3 + \ldots + Z_n,$$

монда $Z_1$, $Z_2$, $Z_3$, …, $Z_n$ – әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы субсидия булган расходлар (чыгымнар).

Әлеге Тәртипнең 11 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән юнәлешләр буенча расходлар (чыгымнар) Министрлык тарафыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын һәм авторлык һәм катнаш хокуклар турында Россия Федерациясе законнарын исәпкә алып билгеләнә.

Әлеге Тәртипнең 11 пунктындагы өченче – егерме беречен абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар (тотымнар) Министрлык тарафыннан тиңдәш эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп, мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре ысулы белән билгеләнә (базарны анализлау).

13. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

«Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә катнашучылар саны – кимендә 10 000;

эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивалендә катнашучылар саны – кимендә 2 000;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, һәр чарада катнашкан муниципаль берәмлекләр саны – кимендә 30;

«Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең үткәрелгән зона этаплары саны – кимендә биш;

эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестиваленең үткәрелгән зона этаплары саны – кимендә өч;

массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Интернет» челтәрендә һәр чараны гамәлгә ашыру турында язмалар саны – һәрберсендә кимендә өч;

«Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең үткәрелгән концертлар саны – кимендә бер;

эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестиваленең үткәрелгән концертлар саны – кимендә бер;

Субсидия бирү нәтиҗәләренә субсидия бирелгән елның 31 декабреннән соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

14. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү төзү даталарына (алга таба - килешү) сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап

алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

15. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Сайлап алуны уздыру турында игълан булдыру һәм урнаштыру тәртибе

16. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлык тарафыннан Министрлык “Электрон бюджет” системасында игъланны формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан һәм субсидия турындагы мәгълүматның бердәм порталында бастырып чыгарылганнан соң урнаштырыла.

17. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 14 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 23 – 28 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Тәртипнең 29 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 32 – 35 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 36 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчеләренә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

конкурста катнашучыларга әлеге Тәртипнең 30 һәм 31 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында игълан итүнең аңлатмаларын бирү тәртибе, мондый бирүне башлау датасы һәм төгәлләү вакыты;

сайлап алуда җиңүчеләр әлеге Тәртипнең 45 пункты нигезендә килешүгә кул куярга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчеләрне әлеге Тәртипнең 7.5 пункты нигезендә килешүләр төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minmol.tatarstan.ru/) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңрак була алмый).

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

18. Министрлык тарафыннан бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

19. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын

тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

20. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

21. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы игълан бердәм порталда урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

22. Әлеге Тәртипнең 18 пункты нигезендә сайлап алуны уздырмау срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) белән килешүләр төзелгәнгә кадәр, Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алу уздырмаска мөмкин.

## V. Заявкаларны формалаштыру һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирү тәртибе

23. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан расланган сайлап алуда катнашучы уставының гамәлдәге редакциясе;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

салым түләүченең индивидуаль номерын бирү турында таныклык;

әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән чыгымнар (тотымнар) юнәлешләре нигезендә чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнарның (тотымнарның) сайлап алуда катнашучы җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) кул куйган сметалары;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта - фактта тотылган чыгымнарны раслый торган документлар күчермәләре (шартнамәләр һәм аларга кушымталар, башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, түләү йөкләмәләре, шулай ук (булган очракта) счетлар, счетлар-фактуралар, сайлап алуда катнашучы җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан таныкланган документлар күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте өлкәсендә, заявка биргән датага кадәрге кимендә биш ел рәттән, тиешле чаралар санап, чаралар уздыру тәҗрибәсенә ия булуы турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) имза куйган гарантияле хат.

24. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

25. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм

дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

26. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

27. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы булып заявкага “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

28. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

салым органында исәпкә куелу сәбәбе датасы һәм коды

юридик затның адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге;

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәсе, соратып алына торган субсидия күләме.

29. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 23 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

30. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр

өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Министрлыкка иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

31. Министрлык әлеге Тәртипнең 30 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VI. Заявкаларны карау, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү кагыйдәләре

32. Министрлык заявкаларны карап тикшерү максатларында комиссия төзи, аңа шул исәптән Министрлыкның иҗтимагый советы әгъзалары кертелә. Комиссиянең составы, комиссиянең эш тәртибе Министрлык тарафыннан раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, комиссия секретареннан, комиссия әгъзаларыннан төзелә.

Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында комиссия тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга Министрлык һәм комиссиягә керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Министрлыкка һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучыларга бирелгән заявкаларга керү ачыла.

33. Комиссия сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик затның адресы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

34. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

35. Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип таныла.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә комиссия тарафыннан кабул ителә.

36. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның һәм (яисә) заявкаларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

37. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

38. Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисе һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

39. Сайлап алу түбәндәге очракларда булмаган дип таныла:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

40. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

41. Сайлап алуда җиңүче булып сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар таныла.

42. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчеләрне ачыклау максатларында сайлап

алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм “Электрон бюджет” системасында комиссия рәисе һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң 14 нче календарь көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенә түбәндәге белешмәләр кертелә:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидиянең күләме.

43. Әлеге Тәртипнең 42 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган субсидия күләмен сайлап алу йомгаклары беркетмәсендә күрсәткәндә ул сораган субсидия күләме әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибенә туры килмәгән очракта комиссия мондый сайлауда катнашучы өчен каралган субсидия күләмен төзәтергә мөмкин, әмма ул заявкада күрсәтелгән күләмнән югарырак булмаска тиеш.

44. Сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия әлеге Тәртипнең 44 пунктында күрсәтелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар арасында түбәндәге ысул белән бүленә: рейтингта беренче тәртип номеры бирелгән сайлап алуда катнашучыга заявкада күрсәтелгән күләмнең мәгънәсенә тигез субсидия күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел.

Рейтингка кертелгән һәр сайлап алуда катнашучыга заявкада күрсәтелгән күләмгә тигез субсидия күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел, күрсәтелгән күләм субсидиянең бүленмәгән күләменнән кечерәк йә аңа тигез булса.

Заявкада сайлап алуда катнашучы күрсәткән субсидия күләме бүленмәгән субсидия күләменнән зуррак булган очракта, сайлап алуда катнашучының ризалыгы белән сайлап алуның мондый катнашучысына калган субсидиянең барлык күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел, сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкада күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре үзгәртелми.

## VII. Килешүләр төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

45. Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүчеләр белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгәннән соң 20 нче эш көненнән дә соңга калмыйча килешү төзи.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә).

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

46. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

47. Министрлык сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

48. Министрлык әлеге Тәртипнең 47 пунктында каралган нигезләрдә сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән срокта сайлап алуда җиңүче килешүне имзаламаган очракта Министрлык сайлап алуның соратып алына торган күләме өлешендә заявкалары тулы күләмдә канәгатьләндерелмәгән сайлап алуда җиңүче дип танылган башка катнашучыларга субсидия күләмен һәм аны бирү нәтиҗәләрен арттыру турындагы тәкъдим җибәрә яки заявкасы кимү тәртибендә киләсе заявка рейтингына ия дип танылган сайлап алуда җиңүче белән килешү төзи.

49. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча сайлап алу җиңүчеләре арасында

бүленмәгән тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше булган, бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырган, җиңүче килешүне төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешүне өзгән очракта, Министрлык әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә өстәмә сайлап алуны уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

50. Агымдагы финанс елы чикләрендә Министрлыкка субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары арттырылган, сайлап алу җиңүчесе килешү төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешү өзелгән һәм сайлап алуны узган һәм субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җитәрлек булмау сәбәпле сайлап алуда җиңүче дип танылмаган яки заявкалары соратып алына торган күләм өлешендә тулы күләмдә канәгатьләндерелмәгән сайлап алуда җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучылар булган очракларда субсидия рейтингта элек бирелгән номерны исәпкә алып кабат сайлап алуны үткәрмичә бүленергә мөмкин.

51. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

52. Субсидия алучыга, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш, акчалар алу тыела (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә).

48. Министрлык килешүләр төзүне төгәлләү срогын сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучыларга субсидияләр бирү турында карар кабул итә, ул Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

54. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

55. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 эш көненнән соңга калмыйча акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

## VIII. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

56. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның

15еннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча түбәндәге хисапларны тапшыра:

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә – субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап;

чыгымнарны каплауга субсидия биргәндә – субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап.

57. Министрлык әлеге Тәртипнең 56 пунктында күрсәтелгән хисапларны әлеге хисаплар бирелгән көннән алып биш эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерә.

58. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерә.

59. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

60. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга тоту ихтыяҗы булган очракта, субсидия алучы Министрлыкка, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, субсидия алучыдан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Субсидия алучының хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында карар булмаган очракта, субсидия алучы әлеге акчаны хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарырга тиеш.

Министрлык тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тәртибендә бирелгән субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен тотуга ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

61. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган очракларда;

әгәр субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидия акчасын түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә (V) кире кайтара:

$$V = S \times k\,,$$

монда:

S – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{t}{n}\,,$$

монда:

t – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең фактта ирешелгән күрсәткечләре;

n – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең план буенча күрсәткечләре.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

62. Субсидияне кире кайтару срогы бозылганда Министрлык срок чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

63. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.